ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 12 2024 г. № 1282

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме, башка социаль гарантияләр һәм түләүләр кысаларында бирелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрне билгеләү һәм күрсәтү процессларын гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 2.7 пункт өстәргә:

«2.7. Техник мөмкинлекләр булганда компенсация бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм) чараларын, социаль хезмәт күрсәтүләрне билгеләү һәм күрсәтү процессларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне

гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы карары нигезендә электрон рәвештә башкарыла.

Күрсәтелгән очракларда компенсация бирү «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән санлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан яисә дәүләт хакимияте органнарының (дәүләт органнарының), җирле үзидарә органнарының, Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминият фонды, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның мәгълүмат системаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов